**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 12 февраль № 78

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 31 октябрь, 822 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы хакимият органнарына, Татарстан Республикасының дәүләт автоном, бюджет учреждениеләренә хезмәт күрсәтүче эш урынындагы җиңел автомобильләрне көн дә карап тотуга норматив чыгымнарны һәм шәхси җиңел автомобильдән эш максатларында файдаланганда компенсациянең иң чик күләмен хисаплап чыгару тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы хакимият органнарына, Татарстан Республикасының дәүләт автоном, бюджет учреждениеләренә хезмәт күрсәтүче эш урынындагы җиңел автомобильләрне көн дә карап тотуга норматив чыгымнарны һәм шәхси җиңел автомобильдән эш максатларында файдаланганда компенсациянең иң чик күләмен хисаплап чыгару тәртибен раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 822 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 7 февраль, 72 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы хакимият органнарына, Татарстан Республикасының дәүләт автоном, бюджет учреждениеләренә хезмәт күрсәтүче эш урынындагы җиңел автомобильләрне көн дә карап тотуга норматив чыгымнарны һәм шәхси җиңел автомобильдән эш максатларында файдаланганда компенсациянең иң чик күләмен хисаплап чыгару тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пункттагы «һәм Татарстан Республикасы министрлыклары, ведомстволарының үзәк аппаратлары хезмәткәрләре өчен командировка чыгымнарын фаразлау һәм планлаштыру максатларында хисаплап чыгарыла торган норматив чыгымнарны» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 нче пунктта:

сигезенче абзацтагы «(командировкаларга бару өчен каралган 25 процентны кертеп)» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«автомобиль йөртүченең туклануына һәм яшәвенә командировка чыгымнары ($З_{8.1}$)»;

4 нче пунктта:

дүртенче – алтынчы абзацлар үз көчен югалткан дип санарга;

җиденче абзацтагы «, автомобиль йөртүчеләрнең туклануына һәм яшәвенә командировка чыгымнары» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«НФЗ_{В2} = 0,5 \times \left(З_{10} + \sum_{j=3}^{8} З_j\right).»;$$

7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Казан шәһәре һәм Яр Чаллы шәһәре өчен $НФЗ_{В1}$ һәм $НФЗ_{В3}$ норматив чыгымнарын хисаплап чыгарганда 1,03 арттыру коэффициенты (халык саны 500 мең кешедән артыграк булган эре шәһәр өчен ягулык-майлау материалларын сарыф итүне исәпкә алып, арттыру коэффициенты буларак) файдаланыла.»;

түбәндәге эчтәлекле 8 нче пункт өстәргә:

«8. Татарстан Республикасы хакимият органнарына, Татарстан Республикасының дәүләт автоном, бюджет учреждениеләренә хезмәт күрсәтүче җиңел автомобильләрдән, шулай ук «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе дәүләт йөкләмәсен формалаштырганда һәм аның үтәлешен финанслар белән тәэмин иткәндә файдаланыла торган эш урынындагы җиңел автомобильләрдән файдаланып командировкаларга барганда ягулык-майлау материалларына норматив чыгымнар ($НФЗ_{В4}$) түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$НФЗ_{В4} = З_8 \times 0,35.».$$

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин